КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 2 март г.Казань № 157

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 17 март, 148 нче карары белән расланган Россия Федерациясе территориясендә һава транспорты белән төбәк эчендә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан һава транспорты оешмаларына субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе территориясендә һава транспорты белән төбәк эчендә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан һава транспорты оешмаларына субсидияләр бирү тәртибе турында» 2016 ел, 17 март, 148 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 30 апрель, 271 нче; 2016 ел, 30 декабрь, 1061 нче; 2017 ел, 24 апрель, 244 нче; 2017 ел, 22 сентябрь, 708 нче; 2018 ел, 26 апрель, 295 нче; 2018 ел, 19 сентябрь, 799 нчы; 2019 ел, 21 март, 198 нче; 2019 ел, 8 май, 386 нчы; 2019 ел, 23 июль, 617 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Россия Федерациясе территориясендә һава транспорты белән төбәк эчендә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан һава транспорты оешмаларына субсидияләр бирү тәртибенә (алга таба – Тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Әлеге Тәртиптә кулланыла торган төшенчәләр Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе территориясендә һава транспорты белән төбәк эчендә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру өчен федераль бюджеттан һава транспорты оешмаларына субсидияләр бирү һәм төбәк маршрут челтәрен формалаштыру турында» 2013 ел, 25 декабрь, 1242 нче карары белән расланган Россия Федерациясе территориясендә һава транспорты белән төбәк эчендә

пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру өчен федераль бюджеттан һава транспорты оешмаларына субсидияләр бирү һәм төбәк маршрут челтәрен формалаштыру кагыйдәләрендә (алга таба – федераль кагыйдәләр) кулланыла торган мәгънәдә кулланыла.»;

3 нче пунктта «авиайөртүчеләргә» сүзләре алдына «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2024 елларга Татарстан Республикасының транспорт системасын үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 20 декабрь, 1012 нче карары белән расланган «2014 – 2024 елларга Татарстан Республикасының транспорт системасын үстерү» дәүләт программасын тормышка ашыру кысаларында» сүзләрен өстәргә;

5 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Субсидияләр әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән максат өчен вәкаләтле органга тиешле финанс елына һәм план чорына билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.»;

6 нчы пунктның икенче абзацында «кушымта» сүзен «1 нче кушымта» сүзләренә алыштырырга;

7 нче пунктның дүртенче абзацында татар текстында «үзгәртеп оештыру, бетерү, банкротлык процессында булмаска» сүзләрен «үзгәртеп оештыру, бетерү процессында булмаска» сүзләренә алыштырырга, «булмаска» сүзеннән соң «, аларга карата банкротлык процедурасы гамәлгә кертелмәгән, субсидия алучыларның эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән каралган тәртиптә туктатылмаган булырга» сүзләрен өстәргә;

9 нчы пунктның өченче абзацына «субсидия» сүзеннән соң «һәм факттагы пассажирлар әйләнешен субсидияләү нәтиҗәлелегенең комплекслы күрсәткече» сүзләрен өстәргә;

10 нчы пунктның дүртенче абзацында «, банкротлык» сүзен төшереп калдырырга, «булмавы» сүзеннән соң «, аларга карата банкротлык процедурасы гамәлгә кертелмәгән, субсидия алучыларның эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән каралган тәртиптә туктатылмаган булуы» сүзләрен өстәргә;

16 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16. Субсидия күләме субсидияләнә торган һәр маршрутка карата бирелә торган субсидияләр күләмнәрен кушу юлы белән исәпләп чыгарыла, шул ук вакытта һәр субсидия башкарылган парлы рейслар санының, бер парлы рейска бирелә торган, әлеге Тәртипнең 1 нче кушымтасында каралган субсидиянең иң чик күләменнән артмый торган субсидия күләменең һәм федераль кагыйдәләргә теркәлгән 5 нче кушымтада китерелгән коэффициентның тапкырчыгышы буларак билгеләнә.»;

17 нче пунктның беренче абзацында «кушымта» сүзен «1 нче кушымта» сүзләренә алыштырырга;

25 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«25. Вәкаләтле орган һәм (яки) Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр йомгаклары буенча әлеге Тәртиптә каралган субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм (яки) тәртибен бозу факты ачыкланган очракта, тиешле акча Татарстан Республикасы бюджеты кеременә түбәндәге нигездә кире кайтарылырга тиеш:

вәкаләтле орган таләбе нигезендә – әлеге таләпне алган көннән 30 көн эчендә;

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының тәкъдиме һәм (яки) күрсәтмәсе нигезендә – Россия Федерациясе Бюджет законнары нигезендә билгеләнгән вакытларда.»;

түбәндәге эчтәлекле 29 һәм 30 нчы пунктларны өстәргә:

«29. Субсидия бирүнең нәтиҗәсе булып вәкаләтле орган белән шартнамә төзегән авиапассажирлар йөртүче тарафыннан һава транспорты белән шартнамәдә каралган санда йөртүләрне гамәлгә ашыру тора.

Әлеге нәтиҗәгә ирешү өчен кирәкле күрсәткеч (аның мәгънәсе шартнамәдә билгеләнә) хисап елы өчен һәр маршрут буенча факттагы пассажирлар әйләнешен субсидияләү нәтиҗәсенең комплексы күрсәткече тора, аның мәгънәсе түбәндәгеләрдән түбәнрәк була:

бу күрсәткечнең федераль кагыйдәләргә теркәлгән 4 нче кушымтада китерелгән, федераль кагыйдәләргә теркәлгән 5 нче кушымтада китерелгән территорияләрнең ераклыгын һәм аларга авыр барып җитүне үз эченә ала торган коэффициентларны исәпкә алып арттырылган иң чик күрсәткечләреннән – федераль кагыйдәләргә теркәлгән 5 нче кушымтага кертелгән Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә урнашкан пунктлардан (пунктларга) маршрутлар өчен;

бу күрсәткечнең федераль кагыйдәләргә теркәлгән 4 нче кушымтада китерелгән әлеге күрсәткечнең иң чик күрсәткечләреннән – башка маршрутлар өчен.

Субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү өчен кирәкле күрсәткечкә һәм субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү турындагы хисап авиапассажирлар йөртүче тарафыннан вәкаләтле органга, субсидия биргән елдан соң килә торган елның 15 гыйнварыннан да соңга калмыйча, әлеге Тәртипкә теркәлгән 2 нче кушымтадагы форма буенча бирелә.

30. Хисап елында субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү өчен кирәкле күрсәткечкә һәм субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешелмәгән очракта, авиапассажирлар йөртүче тарафыннан алынган субсидия акчасы Татарстан Республикасы бюджеты керемена шартнамәдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсе мәгънәсенә ирешмәүгә пропорциональ рәвештә билгеләнә торган күләмдә әлеге Тәртипнең 25 пунктындагы икенче һәм өченче абзацларында каралган тәртиптә кире кайтарылырга тиеш.»;

Тәртипкә теркәлгән кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

Тәртипкә 2 нче кушымта (карарга теркәлә) өстәргә.

2. Бу карарның гамәле 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Россия Федерациясе территориясендә һава транспорты белән төбәк эчендә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан һава транспорты оешмаларына субсидияләр бирү тәртибенә 1 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының
2020 ел, 2 март, 157 нче
карары редакциясендә)

2020 елга Татарстан Республикасы территориясенә һәм (яки) территориясеннән гамәлгә ашырыла торган һава транспорты белән төбәк пассажирлар йөртүнең субсидия бирелә торган маршрутлары
исемлеге

| Т/с | Һава транспорты белән йөртү маршрутлары | | 1 атнага парлы рейслар ешлыгы | 1 елга парлы рейс-лар саны | Махсус тарифның иң чик зурлыгы, сум | 1 парлы рейс өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан авиапассажирлар йөртүчеләргә бирелә торган субсидия күләме, сум | Һава транспорты белән йөртүләрне башкару чоры |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | шәһәр | шәһәр | | | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| 1. | Казан | Пермь | 3 | 156 | 3 225,0 | 72 839,49 | 02.01.2020 – 31.12.2020 |
| 2. | Казан | Түбән Новгород | 4 | 208 | 2 741,0 | 61 691,13 | 02.01.2020 – 31.12.2020 |
| 3. | Казан | Самара | 1 | 52 | 2 258,0 | 50 543,38 | 02.01.2020 – 31.12.2020 |
| 4. | Казан | Оренбург | 4 | 204 | 3 708,0 | 45 269,93 | 01.01.2020 – 31.12.2020 |
| 5. | Казан | Нижневар-товск | 2 | 78 | 9 021,0 | 366 125,0 | 02.01.2020 – 31.12.2020 |
| 6. | Казан | Сургут | 2 | 78 | 8 538,0 | 366 125,0 | 02.01.2020 – 31.12.2020 |
| 7. | Казан | Яңа Уренгой | 2 | 78 | 9 987,0 | 366 125,0 | 02.01.2020 – 31.12.2020 |
| 8. | Казан | Омск | 3 | 112 | 8 538,0 | 223 336,25 | 02.01.2020 – 31.12.2020 |
| 9. | Казан | Барнаул | 2 | 104 | 10 953,0 | 223 336,25 | 02.01.2020 – 31.12.2020 |
| 10. | Казан | Махачкала | 2 | 104 | 8 055,0 | 223 336,25 | 02.01.2020 – 31.12.2020 |
| 11. | Казан | Чиләбе | 2 | 104 | 4 764,0 | 106 282,74 | 02.01.2020 – 31.12.2020 |
| 12. | Казан | Ярославль | 2 | 104 | 3 708,0 | 83 987,24 | 02.01.2020 – 31.12.2020 |
| 13. | Казан | Воронеж | 2 | 104 | 4 764,0 | 104 540,4 | 01.01.2020 – 31.12.2020 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 14. | Казан | Калуга | 2 | 104 | 5 157,0 | 115 506,0 | 01.01.2020 – 31.12.2020 |
| 15. | Казан | Брянск | 2 | 104 | 6 123,0 | 137 436,0 | 01.01.2020 – 31.12.2020 |
| 16. | Казан | Кемерово | 2 | 104 | 10 953,0 | 223 336,25 | 02.01.2020 – 31.12.2020 |
| 17. | Казан | Волгоград | 2 | 104 | 5 157,0 | 117 431,1 | 02.01.2020 – 31.12.2020 |
| 18. | Казан | Ростов-на-Дону | 3 | 39 | 6 606,0 | 172 118,82 | 01.01.2020 – 31.03.2020 |
| 19. | Нижне-камск | Ростов-на-Дону | 2 | 105 | 7 089,0 | 189 251,89 | 01.01.2020 – 31.12.2020 |
| 20. | Нижне-камск | Краснодар | 3 | 65 | 8 055,0 | 492 722,62 | 01.01.2020 – 31.05.2020 |
| 21. | Нижне-камск | Новосибирск | 2 | 105 | 10 470,0 | 237 257,67 | 01.01.2020 – 31.12.2020 |
| 22. | Бугульма | Нижневар-товск | 2 | 78 | 8 538,0 | 366 125,0 | 02.01.2020 – 31.12.2020 |
| 23. | Бугульма | Сургут | 2 | 78 | 8 055,0 | 366 125,0 | 02.01.2020 – 31.12.2020 |
| 24. | Бугульма | Яңа Уренгой | 3 | 116 | 9 987,0 | 366 125,0 | 02.01.2020 – 31.12.2020 |
| 25. | Бугульма | Ноябрьск | 2 | 53 | 8 538,0 | 366 125,0 | 02.01.2020 – 31.12.2020 |
| 26. | Бугульма | Усинск | 2 | 78 | 7 089,0 | 274 748,0 | 02.01.2020 – 31.12.2020 |

Россия Федерациясе территория-сендә һава транспорты белән төбәк эчендә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан һава транспорты оешмаларына субсидияләр бирү тәртибенә
2 нче кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 2 март, 157 нче
карары редакциясендә)

Форма

________________________________________________________________________
(оешманың тулы исеме)

субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү өчен кирәкле күрсәткечкә һәм
субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү турында
хисабы

20__ елның ____________ ыннан 20__ елның ____________ ына кадәр

| Нәтиҗәнең исеме | Маршрут | | Нәтиҗәнең план буенча мәгънәсе | Нәтиҗәнең факттагы мәгънәсе | Үтәү про-центы | Фактта йөртелгән пассажирлар саны | Факттагы пассажирлар әйләнешен субсидияләү нәтиҗәсенең комплекслы күрсәткече |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | утырып кителә торган аэро-порт | барып җителә торган аэропорт | | | | | |
| | | | | | | | |

Оешма җитәкчесе

__________________________ __________________________
(имзасы) (фамилиясе, исеме, атасының исеме)

20_ ел, «__» ____________

М.У. (булганда)

________________________________